ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УРАЗАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
423750, Уразай авылы,
Центральная ур., 4 йорт

СОВЕТ УРАЗАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423750, дер.Уразаево, ул.
Центральная, дом 4

**КАРАР**
**17 .09.2019 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№23**

**Референдум үткәрү инициативасы турында**

12.06.2002 ел,№ 67-ФЗ “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12, 17 статьялары, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының “Уразай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Советы

**Карар чыгарды:**

1. Түбәндәге мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне инициировать итергә:

"2020 елда 18 яшькә җиткән, яшәү урыны җирлек чикләрендә теркәлгән һәр гражданнан 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертүгә, аларның җирле референдумда катнашуына һәм тавыш биргәндә билгеләнгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, көндезге формада белем алучы студентлар, 1 төркем,балачактан инвалидлар, аларның саны җирлек халкының гомуми саныннан 30 проценттан да артмый, алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү турында:

“ӘЙЕ” “ЮК”

-торак пунктларда су челтәрләрен ремонтлау, карап тоту, су чыганакларын ремонтлау һәм лицензияләү;
- сабантуй үткәрү урыннарын төзекләндерү;
- рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын оештыру һәм уздыру ;
- зират территориясендә агач кисү;
- авыл җирлеге территориясендә агач кисү;
-ритуаль хезмәтләр өчен инвентарь сатып алу;
- зират коймасын ремонтлау;
-юлларны ремонтлау һәм карап тоту (ПГС һәм ЩПС салу, грейдерлау, кардан чистарту)
- һәйкәлне ремонтлау һәм реконструкцияләү ;
- җирлек торак пунктларында хуҗасыз территорияләрне ремонтлау һәм киртәләү;
-торак пунктларда урам исемнәре һәм йорт номерлары булган күрсәткечләр урнаштыру;
-урамнарнын яктырту электр челтәрләрен карап тоту;
- декларация алдыннан ГТСны тикшерү.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнаштырылган махсус мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә: ТР, Актаныш муниципаль районы, Уразай авылы, Үзәк урам, 4 нче йорт, Куян авылы, Үзәк урам,57 нче йорт, Мерэс авылы, Үзәк урам,35а нче йорт, Ильчебай авылы, Үзәк урам,19 нче йорт, Шәрип авылы, Үзәк урам, 5 нче йорт Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмати порталында һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Уразай авыл җирлеге башлыгы: Шарипов Р.Р.